СОВЕТ УСАДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район,
д.Тимофеевка, ул.Профсоюзная, 45

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСАД АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Тимофеевка авылы, Профсоюз урамы, 45

тел./факс 8(84365) 73-2-75, e-mail:Usad.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**5 июль 2023 ел** **№ 75**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге органнарының муниципаль хезмәткәрләренә даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 30 апрелендәге 128 номерлы Усад авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Усад авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге Советына таянып, законнарга туры китерү максатларында

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге органнары муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 30 апрелендәге 128 номерлы Усад авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (2020 елның 30 сентябрендәге 4 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып):

- 1 п.1 пунктында 15 абзацны төшереп калдырырга;

- «Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен айлык процент өстәмәләре күләме һәм муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи оклады күләмен» 12 нче кушымтаны төшереп калдырырга;

- Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер мәртәбә бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе турындагы нигезләмәне 12 нче кушымта дип санарга.

2. Әлеге карар рәсми чыгарылган көннән үз көченә керә.

3. Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән әлеге карар ачыклансын http://pravo.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Сибгатуллин